ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«2023 елда Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил эшчәнлеге нәтиҗәләре һәм Татарстан Республикасында бала хокукларының һәм законлы мәнфәгатьләренең үтәлеше турында» Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил доклады хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

1. «2023 елда Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил эшчәнлеге нәтиҗәләре һәм Татарстан Республикасында бала хокукларының һәм законлы мәнфәгатьләренең үтәлеше турында» Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил докладын игътибарга алырга.

2. Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилгә балалар мәнфәгатьләрендәге мәсьәләләрне хәл итүдә коммерциягә карамаган оешмалар белән үзара хезмәттәшлек тәҗрибәсен дәвам итәргә.

3. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комитетларына бала хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итү өлешендә законнарны гамәлгә ашыруны тикшереп тору эшен дәвам итәргә.

4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына, республика башкарма хакимият органнарына, муниципаль районнар һәм шәһәр округлары башлыкларына «2023 елда Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил эшчәнлеге нәтиҗәләре һәм Татарстан Республикасында бала хокукларының һәм законлы мәнфәгатьләренең үтәлеше турында» Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил докладындагы тәкъдимнәрне гамәлгә ашыру чараларын күрүне тәкъдим итәргә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Ю.З. Камалтыновка йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе
вазыйфаларын башкаручы — Ю.З. Камалтынов

Казан шәһәре,
2024 елның 29 марты
№ 2391-VI ДС